ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 3** **«27» гыйнвар 2015 ел**

2014 елның 5 ноябрендәге Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 18 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясе чикләрендә йөрү, яшәү һәм яшәү урынын сайлау ирегенә Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 387-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2014 елның 31 декабрендәгә гамәлгә керү һәм Ютазы районы прокурорының 2015 елның 21 гыйнварындагы 02-08-01-2015 протесты сәбәпле

1. 2014 елның 5 ноябрендәге Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 18 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетында белешмә (өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтүнең административ регламентының «мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документларның тулы исемлеге» 2 нче кушымтаның 4 нче пункты, карарның 1 нче кушымтасы белән расланган, түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Хуҗалык китабынан өземтә алу өчен:

1. Хуҗалык китабы күчермәсен иректә формада бирү турында гариза.
2. Хокук иясе шәхесен раслаучы Документ.
3. Үлгән җир участогы хуҗасының үлем таныклыгының күчермәсе;
4. Җир кишәрлегендә урнашкан йортка (башка объектлар булса) хокук билгеләүче документларның күчермәләре;
5. Җир участогында урнашкан йортның адрес номеры күрсәтелгән фотосы.»

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендәге мәгълүмат стендында һәм рәсми сайтында бастырып чыгарырга www.yutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев

Зарипова Р.В.
4-21-34